**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3045**
**14.06.2019**

Башкарма комитетның «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 25 мартындагы 1316 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 5 мартындагы 1144 нче карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 25 мартындагы 1316 нчы карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3251 нче, 2017 елның 3 маендагы 2748 нче, 2017 елның 11 июлендәге 4092 нче, 2018 елның 21 декабрендәге 7675 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

2) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча раслырга.»;

3) мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

- исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»;

- 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – административ регламент) Яр Чаллы шәһәрендә мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына мәктәпкәчә яшьтәге балаларны исәпкә кую һәм аларны кабул итү (алга таба – муниципаль хезмәт) тәртибен билгели.»;

- 2.1 пунктта стандартка карата таләпләрнең эчтәлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин